**Профсоюз эшчәнлегенә отчет!**

Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар!

Профсоюзның мәгариф һәм социаль-хезмәт өлкәләрендәге эшчәнлеге профсоюз әгъзаларының тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән: матди иминлекне арттыру, сәламәтлекне саклау, хезмәт нормаларын камилләштерү, мәгариф һәм мәдәни ихтыяҗларны канәгатьләндерү, һөнәри осталыкны  гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру. Профсоюз структурасының барлык дәрәҗәләрендә практик эше лаеклы, гадел һәм ачык хезмәт өчен түләү системасын, куркынычсыз, сәламәт хезмәт һәм укыту шартларын, психологик уңайлыкны, оптималь һәм сыгылмалы эш графигын, гомер буе дәвамлы һөнәри белем бирүне тәэмин итүне үз эченә ала.

2023-2024 нче уку елында барлыгы 74 профсоюз члены. Һәр профсоюз членының профсоюз билетлары кәгазь профсоюз билетлары электрон билетларга алыштырылды. Хәзер, һәр әгъза Пластик карта профсоюз билетына ия яки мобиль кушымтада профсоюз билетының виртуаль дубликатын куллана.

Шулай ук электрон учет тәртибе барлыкка килде һәм статистик хисап отчетлары да әлеге формада тапшырыла. Бердәм электрон база булдырылды. Барлык 1% күләмендә кергән профсоюз взнослар, акча әйләнеше, керем һәм чыгымнар да үтә күренмәле.

Шулай ук профсоюз мәгълүмат ресурсларының имиджына һәм аларны бердәм корпоратив стильгә китерүгә аерым игътибар бирелде. Беренчел оешмаларның «Татарстан Республикасының Электрон мәгариф" порталында урнашкан Профсоюз бүлекләре бертөрлелеккә китерелде һәм эчтәлек яңартылды, оешманың да битләрен Электронное образование порталында күренеп тора.

Республика профсоюз оешмасы, социаль партнерлыкның төрле формаларын киң кулланып, социаль проектларга һәм программаларга һәрвакыт аерым игътибар бирә. Профсоюз членнарын санаторийларда  савыктыру аеруча актуаль булып кала. Профсоюз члены ташламалы санатор-курорт юлламалары белән тәэмин ителде. 2023 нче елда мәгариф хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы, ягъни сертификатлар белән тәэмин итүгә күчү турындагы тәкъдимне хупладылар һәм бу өлкәдә инде эш башланды, 2 профсоюз члены Сосновый Борда хәм Ижминводы да ял итеп кайттылар, бер профсоюз членына 25 000 сум күләмендә 6

көнгә сертификат бирелде, әгәр дә көнен озынайтасы килә икән, остәмә акча түләп тә була.

Соңгы 2 елда "Ярты бәягә юллама" проекты барлыкка килде. Профсоюз юллама бәясенең 50% ка кадәр Профсоюз ташламалары белән шифаханәләрдә ял итәргә тәкъдим итә. Ике ел эчендә ташламалы юлламалардан профсоюз членнары файдаланып ял итеп кайттылар. Азнакай шәһәрендә урнашкан санаторийда 1 прфсоюз члены шушы ташлама белән ял итеп кайтты.

ТРсы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен дәүләтнеке булмаган пенсия белән тәэмин итү программасы уңышлы тормышка ашырыла. 15 ел дәвамында мәгариф хезмәткәрләре пенсиягә чыккач һәм эш урынын калдырганнан соң республика бюджеты акчалары исәбеннән дәүләтнеке булмаган пенсия фондыннан өстәмә акча ала. Программада мәгариф хезмәткәре катнаша, шулай ук 2023 елның 1 гыйнварыннан «Пенсиягә профсоюз бонусы» дигән яңа проект гамәлгә ашырыла башлады, ягъни өстәмә тагын 300 сум бирелә. Әлеге бонусны исә лаеклы ялдагы хезмәткәрләр ала башлады.

Хезмәткәрләргә социаль-экономик гарантияләрне бирүнең хокукый нигезе 2021-2023 нче елларга 3 яклы (Мөслим башкарма комитеты, мәгариф идарәсе һәм мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмалары советы) төзелгән килешүләр нигезендә алып барылды. Килешүдә башка еллардан аермалы буларак, һәр профсоюз әгъзасына социаль хокуклар һәм ярдәм каралган. Шушы килешүләр нигезендә, урыннарда коллективта администрация белән профсоюз комитеты арасында 2021-2023 нче елларга коллектив договорлары, ягъни килешүләре төзелде һәм районның хезмәт һәм мәшгульлек үзәгендә регистрациягә алынды. Шуны искәртергә кирәк: коллектив килешүләренең кушымталары (мәсәлән, өстәмә түләүләр, өстәмә ял, эчке тәртип кагыйдәләрендәге үзгәрешләр) үз вакытында коллективка җиткерелми. Урыннарда коллектив килешүләрдә каралган ташламаларның үтәлүенә контроль җитеп бетми. Шул сәбәпле хезмәткәрләрнең хезмәт, профессиональ, социаль-экономик хокуклары бозыла һәм аларны тикшерү, ачыклау, аңлату эшләрен бертөзлексез башкарырга туры килә.

Килешү төзүнең төп максаты администрация белән профсоюз комитеты арасында социаль партнерлыкны үстерү түгел, ә бәлки закон нигезендә хезмәткәрләргә бирелгән хокук һәм гарантияләрне

тормышка ашыруны тәэмин итү. Шуңа күрә профсоюз органнарының хезмәткәрләрнең социаль статусларын күтәрү юнәлешендә ныклап эшләве мөһим.

2022 нче елның күләмле хезмәте дип, Гомумроссия мәгариф профсоюзының Татарстан Республика оешмасы, Татарстан Республикасы профсоюзлар Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән берлектә, авыл педагогларына җылылык өчен компенсацияләр эзләде. Чөнки түләү механизмы билгеләнмәде. Ниһаять, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 588 номерлы карары белән җылыту чорында торак урыннары, җылылык һәм яктырту өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү өчен аена 1200 сум күләмендә билгеләнде. Әлеге компенсацияне 42 педагогик хезмәткәр һәм лаеклы ялдагы хезмәткәрләр ала башлады.

Профсоюз оешмалары Советы, урыннарда профсоюз комитетлары тарафыннан культура-масса, спорт-сәламәтләндерү эшләрен үстерү юнәлешендә дә күләмле эшләр эшләнде. Бәйрәмнәрне күңелле итеп үткәрү, спорт-сәламәтлек чаралары һәрдаим үтеп тора. Мәгариф хезмәткәрләрен ял иттерү максатыннан: район мәдәният йортына килгән 2 концертка 20 профсоюз членына ярты бәягә билетлар алып бирелде, укытучылар көнен билгеләп үтү, мәгариф өлкәсендә эшләүче һәм аларның 11 нче сыйныфны бетерүче балаларын котлау, 8 март һәм 23 февраль бәйрәмнәре белән котлау, некрологлар бирү, профсоюз әгъзаларының әти-әниләре, гаилә әгъзалары вафат булган очракта бирелә торган материал ярдәм, яңа ел бәйрәмен уздыру өчен профсоюз бюджетыннан акчалар тотыла. Укытучылар көнен билгеләп үтүгә, 8 март һәм 23 февраль бәйрәмнәре белән котлау, яңа ел бәйрәмен уздыру өчен профсоюз бюджетыннан 35 000 сум күләмендә акча бирелде, 7 профсоюз членына 1000 шәр сумнан 7 000 сум, газетага некролог бирүгә 3850 сум күләмендә акча бирелде,юбилярны котларга 1000 сум, түләүле операция ясаткан профсоюз членына да ярдәм күрсәтелде, мәктәбебезнең юбилеен үткәрергә дә профсоюз бюджетыннан 10 000 сум күләмендә ярдәм ителде. Профсоюз оешмасы һәрвакыт һәр профсоюз членына ярдәм күрсәтү ягында. Бердәм булып, тату гына шушы өлкәдә эшләребезне күрсәтик.

Профсоюз комитеты рәисе: Амирова М.Р.